ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 декабрь 2024ел № 8040

Башкарма комитетның «Сатулар үткәрмичә муниципаль милектәге җир участогын арендага, түләү нигезендә милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 маендагы 3676 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 9 пункты, «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 492-ФЗ номерлы Федераль законның 4 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Сатулар үткәрмичә муниципаль милектәге җир участогын арендага, түләү нигезендә милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 маендагы 3676 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2024 елның 5 сентябрендәге 5728 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «җир участогын» сүзләреннән соң «муниципаль милектәге» сүзләрен өстәргә;

2) административ регламентта:

- исемне яңа редакциядә бәян итәргә: «Сатулар үткәрмичә муниципаль милектәге җир участогын арендага, түләү нигезендә милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»;

- 1.1 пунктта «җир участогын» сүзләреннән соң «муниципаль милектәге» сүзләрен өстәргә;

- 2.1 пунктта «җир участогын» сүзләреннән соң «муниципаль милектәге» сүзләрен өстәргә;

- 2.8.2.1 пунктта:

8 пунктчада «территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә» сүзләреннән соң «яисә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта» сүзләрен өстәргә.

9 пунктчада «территорияне, яки» сүзләрен «территорияне яисә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, яки» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктчада «аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән» сүзләрен «аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән яисә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктчада «бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру» сүзләрен «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырырга;

- 5 нче кушымтада:

исемне яңа редакциядә бәян итәргә: «Гариза бирүченең муниципаль милектәге җир участогын арендага, түләү нигезендә милеккә алу хокукын раслый торган документлар исемлеге»;

11 пунктта «бакчачылык» сүзен «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктта «Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә» сүзләрен «Территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктта «бакчачылык яки яшелчәчелек» сүзләрен «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктта «әлеге күчемсез милек объектлары бирелгән» сүзләрен «дәүләт яки муниципаль милектәге биналар, корылмалар арендага бирелгән» сүзләренә алмаштырырга;

32 пунктта текст буенча «бакчачылык» сүзен «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов